ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы орденнары, орден медале һәм медальләре**

Татарстан Республикасының түбәндәге орденнары, орден медале һәм медальләре гамәлгә куела:

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены;

«Дуслык» ордены;

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале;

«Фидакарь хезмәт өчен» медале;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале;

«Ана даны – Материнская слава» медале;

«Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медале;

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ статья өстәргә:

«$11^1$ статья. **«Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медале турында нигезләмә**

1. «Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медале белән Татарстан Республикасы дәүләтчелеге үсешенә, аның социаль-икътисадый мөмкинлекләрен, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга, мәдәни-рухи мирасны саклауга һәм арттыруга зур өлеш керткән, һөнәри һәм иҗтимагый эшчәнлектә Татарстан Республикасы абруен арттырырга ярдәм итә торган зур казанышларга ирешкән гражданнар бүләкләнә.

2. «Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Ана даны – Материнская слава» медаленнән соң урнаштыралар.»;

3) 12 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медаленнән соң урнаштыралар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 30 сентябрь
№ 75-ТРЗ